| | | |
|---|---|---|
| **ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ НУРЛАТСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН** | | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ** |

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

19.12.2018 № 1036

Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының 2012 ел, 16 октябрь, 1387 нче карарына үзгәрешләр кертү турында

Кадрлар үзгәрешләре белән бәйле рәвештә, гамәлдәге торак законнарын тормышка ашыруны тәэмин итү максатларында

КАРАР БИРӘМ:

1. «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының иҗтимагый торак комиссиясен төзү турында» 2012 елның 16 октябрендәге 1387 номерлы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының иҗтимагый торак комиссиясе составын яңа редакциядә расларга (1 нче кушымта).

1.2. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының иҗтимагый торак комиссиясе турындагы нигезләмәне яңа редакциядә (2 нче кушымта) расларга.

2. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасарына йөкләргә.

Җитәкче Л.Н. Маняпов

Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының
2018 ел, 19 декабрь, 1036 нчы
карарына 1 нче кушымта

**Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының иҗтимагый торак комиссиясе составы**

Комиссия рәисе:

Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасары Рәхмәтуллин Фәнис Әнәс улы.

Комиссия рәисе урынбасары:

Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының торак сәясәте бүлеге башлыгы Долгова Наталья Иван кызы.

Комиссия секретаре:

Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының торак сәясәте бүлеге әйдәп баручы белгече Сәлахова Мәдинә Хәбибулла кызы.

Торак комиссиясе әгъзалары:

1. Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының яшьләр эшләре һәм спорт бүлеге җитәкчесе вазифаларын башкаручы Бакирова Венера Шәрифулла кызы.

2. Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының юридик бүлеге башлыгы Вәлиәхмәтова Гөлия Фәрит кызы.

3. Татарстан Республикасы хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Нурлат муниципаль районындагы социаль яклау бүлеге башлыгы Терентьева Оксана Геннадий кызы (килешү буенча).

4. Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының опека һәм попечительлек бүлеге җитәкчесе Савинова Ирина Евгений кызы (килешү буенча).

5. Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык бүлеге әйдәп баручы белгече Андарова Лилия Илгизәр кызы (килешү буенча).

6. Нурлат муниципаль районы авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсенең 2 разрядлы өлкән белгече Баймачева Марина Константин кызы (килешү буенча).

7. «Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт торак фонды» КБО вәкиле Васильева Ольга Терентий кызы (килешү буенча).

8. Нурлат муниципаль районы һәм Нурлат шәһәре ветераннар (пенсионерлар) җирле иҗтимагый оешмасы рәисе Садретдинова Разия Идрис кызы (килешү буенча).

9.Мәгариф учреждениеләренең профсоюз оешмалары Нурлат Советы рәисе Сәгыйрова Фәридә Мөхлис кызы (килешү буенча).

10. Агросәнәгать комплексы хезмәткәрләренең район профсоюз оешмасы рәисе Фәйзуллина Тәнзилә Һади кызы (килешү буенча).

Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының

2018 ел, 19 декабрь, 1036 нчы

карарына 2 нче кушымта

**Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының иҗтимагый торак комиссиясе турында нигезләмә**

1. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының иҗтимагый торак комиссиясе (алга таба – Комиссия) гамәлдәге торак законнарын гамәлгә ашыру эшчәнлеген камилләштерү максатларында төзелә һәм үз эшчәнлегендә: Россия Федерациясе Конституциясе, Татарстан Республикасы Конституциясе, Россия Федерациясе Торак кодексы, «Ветераннар турында» 1995 елның 12 гыйнварындагы 5-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасы Дәүләт торак фондыннан һәм муниципаль торак фондыннан социаль наем шартнамәләре буенча гражданнарга торак урыннары бирү хокукларын гамәлгә ашыру турында» 2007 елның 13 июлендәге 31-ТРЗ номерлы, «Татарстан Республикасында торак төзелешен үстерүгә дәүләт ярдәме турында» 2004 ел, 27 декабрь, 69-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы законнары, 2017 ел, 30 декабрь, 1710 нчы карары белән расланган «Россия Федерациясе гражданнарын һәркем алырлык һәм уңайлы торак һәм коммуналь хезмәтләр белән тәэмин итү» Россия Федерациясе дәүләт программасын раслау хакында» һәм 2012 ел, 14 июль, 717 нче карары белән расланган «2013-2020 елларга авыл хуҗалыгын үстерү һәм авыл хуҗалыгы продукциясе, чимал һәм азык-төлек базарларын җайга салу дәүләт программасы турында», 2006 елның 21 мартындагы 153 нче «Россия Федерациясе гражданнарын һәркем өчен мөмкин булган һәм уңайлы торак һәм коммуналь хезмәтләр белән тәэмин итү» Россия Федерациясе дәүләт программасы» Россия Федерациясе Хөкүмәте карарлары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2006 ел, 7 июнь, 275 нче карары белән расланган «Гражданнарның аерым категорияләренә федераль бюджеттан бүлеп бирелә торган субвенцияләр исәбеннән торак сатып алу өчен субсидияләр бирү турындагы нигезләмәне раслау хакында», «2014-2020 елларга Татарстан Республикасы халкын сыйфатлы торак һәм торак-коммуналь хуҗалык хезмәтләре күрсәтү белән тәэмин итү» дәүләт программасын раслау хакында» 2014 ел, 30 апрель, 289 нчы карары, 2005 ел, 15 апрель, 190 нчы карары белән расланган «Татарстан Республикасында социаль ипотека системасында торак шартларын яхшыртуга мохтаҗларны исәпкә кую кагыйдәләрен һәм тәртибен раслау турында», «Торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ күпбалалы гаиләләрне торак белән тәэмин итү буенча өстәмә чаралар турында» 2007 ел, 18 декабрь, 732 нче карары, «Инвалидларның аерым категорияләренә Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән торак урыны сатып алуга торак субсидиясе (бер тапкыр акчалата түләү) бирү турында» 2016 ел, 18 апрель, 236 нчы карары, 2018 елның 29 маендагы 407 номерлы «Авыл территорияләрен тотрыклы үстерү» ярдәмче программасын гамәлгә ашыру турында» карары, 2018 ел, 7 июнь, 432 нче карары белән расланган «Социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча торак урыннары бирүгә мохтаҗ гражданнарны исәпкә алу тәртибе», гамәлдә

булган Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнары һәм әлеге Нигезләмәгә таяна.

2. Комиссия Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты карары белән төзелә. Аның составына комиссия рәисе-Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасары; комиссия рәисе урынбасары – Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының торак сәясәте бүлеге башлыгы; комиссия секретаре – Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының торак сәясәте бүлеге әйдәп баручы белгече керә; Комиссия әгъзалары: Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының яшьләр эшләре һәм спорт бүлеге башлыгы; Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының юридик бүлеге башлыгы; Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының социаль яклау бүлеге башлыгы (килешү буенча); Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының опека һәм попечительлек бүлеге башлыгы (килешү буенча); Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының төзелеш һәм ТКХ бүлеге әйдәп баручы белгече (килешү буенча); Нурлат муниципаль районы авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсенең 2нче разрядлы өлкән белгече (килешү буенча); «Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт торак фонды» КБО вәкиле (килешү буенча); Нурлат муниципаль районы һәм Нурлат шәһәре ветераннар (пенсионерлар) җирле иҗтимагый оешмасы рәисе (килешү буенча); мәгариф учреждениеләре профсоюз оешмаларының Нурлат Советы рәисе (килешү буенча); агросәнәгать комплексы хезмәткәрләренең район профсоюз оешмасы рәисе (килешү буенча).

3. Комиссия эшчәнлеген аның рәисе җитәкли. Комиссия рәисе булмаган очракта аның бурычлары аның урынбасарына йөкләнә.

4. Комиссия утырышлары кирәк булган саен үткәрелә һәм алар эшендә комиссия составының яртысыннан артыгы катнашса, мәсьәләләр хәл итәлергә хокуклы булып санала. Комиссия карары утырышта катнашучыларның күпчелек тавышы белән кабул ителә һәм беркетмә һәм (яки) боерык белән рәсмиләштерелә, соңгысы исә комиссиянең барлык әгъзалары тарафыннан имзалана һәм комиссия рәисе тарафыннан раслана.

5. Комиссиягә түбәндәге функцияләр йөкләнә:

гаризаларны, аларга теркәлгән документларны һәм гражданнарның торак шартларын тикшерү материалларын карау;

гражданнарны торак шартларын яхшыртуга мохтаҗлар дип тану һәм (яисә) торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ дип тану турында яисә гражданнарны исәпкә алудан яисә исәпкә алудан баш тарту турында, федераль бюджет, РФ субъекты бюджеты акчалары исәбеннән бирелә торган торак субсидиясен алу хокукы турында, гражданнарны торак программаларында катнашучылар составына кертү турында тәкъдимнәр кертү хакында;

закон нигезендә «Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт торак фонды» КБО тарафыннан бирелә торган социаль ипотека буенча торак шартларын яхшыртуга гариза бирүчеләрнең реестрын килештерү;

торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ гражданнарны дөрес исәпкә алуны тәэмин итү, дәүләт һәм муниципаль милектә булган торак мәйданын бүлү, гражданнар торакка хокукларын гамәлгә ашыру өчен шартлар тудыру;

закон нигезендә карар кабул итү өчен кирәкле документларның тулылыгын тикшерү;

торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ гражданнарны исәптән төшерү (торак урыннары алу), торак субсидиясен алырга хокуклы гражданнарны торак шартларын яхшыртуга мохтаҗлар исемлегеннән төшереп калдыру (торак урыннары алу), турында карар кабул итү;

дәүләт сертификаты, социаль түләү алырга теләгән гражданнар категорияләре исемлеген төзү.

6. Комиссия хокуклы:

үз утырышларында аның компетенциясендәге мәсьәләләрне карарга;

торак мәсьәләләрен карау өчен милек формасына бәйсез рәвештә дәүләт органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан, оешмалардан кирәкле белешмәләр, документлар һәм аңлатмалар соратып алырга;

комиссия утырышына вазыйфаи затларны, белгечләрне һәм гражданнарны, алардан кирәкле мәгълүмат алу һәм торак мәсьәләләрен караганда аңлатмалар алу өчен, чакырырга;

Нурлат муниципаль районы территориясендә яшәүче гражданнарның торак шартларын тикшерү актын төзү белән яшәү урыны буенча чыгарга;

үз компетенциясе чикләрендә карала торган мәсьәләләр буенча карарлар кабул итәргә һәм аларны беркетмәләр белән рәсмиләштерергә;

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетында торак шартларын яхшырту (торак урыннарын алу) өчен исәптә торучы гражданнарның гаризаларын һәм шикаятьләрен карарга.

7. Коррупция очракларына юл куймау максатыннан, комиссия әгъзалары үз компетенциясендәге мәсьәләләр шәхсән яисә аларның туганнарына кагылышлы сораулар каралган очракта үзләренең катнашмаулары турында белдерә.

8. Комиссия эшчәнлеге Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты карары белән гамәлдәге законнар нигезендә туктатыла.